| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |

**Аларны гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлекләрен сатуга куймыйча арендага бирү рөхсәт ителгән масштаблы инвестиция проектлары туры килергә тиешле критерийларның сыйфат һәм сан күрсәткечләренә үзгәрешләр кертү турында**

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләрен үстерүгә булышлык итү максатларында **карар бирәм:**

1. Аларны гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлекләрен сатуга куймыйча арендага бирү рөхсәт ителгән масштаблы инвестиция проектлары туры килергә тиешле критерийларның Татарстан Республикасы Президентының «Аларны гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлекләрен сатуга куймыйча арендага бирү рөхсәт ителгән масштаблы инвестиция проектлары туры килергә тиешле критерийларның сыйфат һәм сан күрсәткечләрен билгеләү турында» 2015 елның 7 декабрендәге ПУ-1170 номерлы Указы белән билгеләнгән сыйфат һәм сан күрсәткечләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) «Эш урыннары булдыру яисә аларның санын арттыру» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| « | Эш урыннары булдыру яисә аларның санын арттыру | Инвестиция проекты алар урнашкан территориядәге муниципаль берәмлектә эш урыннары санын авыл һәм шәһәр җирлекләре территорияләрендә кимендә 50 эш урынына яисә шәһәр округлары территорияләрендә 100 эш урынына яисә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләрендә, аның резиденты тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе төзү турында карарында билгеләнгән икътисадый эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырганда кимендә 30 эш урынына, шул исәптән юридик зат алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентлары реестрына кертелгәннән соң бер ел дәвамында – 20 эш урынына арттыру мөмкинлеге бирәчәк объектлар төзүне күздә тота | »; |

б) «Кертеләчәк инвестицияләр күләменә таләпләр» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| | |
|---|---|
| Кертеләчәк инвестицияләр күләменә таләпләр | Инвестиция проектында гомуми күләме 350 миллион сумнан артык булган инвестицияләр яисә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләрендә, аның резиденты тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе төзү турында карарында билгеләнгән икътисадый эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырганда гомуми күләме 50 миллион сумнан артык булган, шул исәптән юридик зат алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентлары реестрына кертелгәннән соң бер ел дәвамында – 5 миллион сум капиталь кертемнәр кертү күздә тотыла |

».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2016 ел, 03 ноябрь
№ ПУ-981